-

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чалпы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чалпы авылы № 72 25 сентябрь 2017 ел

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча Чалпы авыл җирлеге территориясендә җирле референдум билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнарының сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы нигезендә 24.03.2004 № 23-ТРЗ «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районының «Чалпы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 12 статьясы белән, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл җирлеге Башкарма комитетының «референдум үткәрү инициативасы турында» 2017 елның 11 сентябрендәге 16 номерлы карарын, Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Чалпы авыл Советының «референдум үткәрү инициативасы турында»2017 елның 11 сентябрендәге 69 номерлы карарын карап,

Чалпы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. 2017 елның 19 ноябренә Чалпы авыл җирлеге территориясендә гражданнарга үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдум билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Чалпы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, көндезге формада укучы студентлардан, 1 һәм 2 төркем инвалидлардан тыш, 2018 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтүгә ризамы Сез?:

1) җирлек торак пунктлары чикләрендәге җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге (авыл җирлеге торак пунктлары юлларын вак таш белән каплау);
2) җирлек халкының ялын оештыру һәм мәдәният оешмалары хезмәтләре белән тәэмин итү (бәйрәм чараларын оештыру һәм үткәрү)өчен шартлар тудыру;
3) җирлек халкының күпләп ял итүе өчен шартлар тудыру һәм халыкның күпләп ял итү урыннарын төзекләндерүне оештыру, моңа гражданнарның

гомуми файдаланудагы су объектларына һәм аларның яр полосаларына ирекле керүен тәэмин итү дә керә (Чалпы авылында паркны төзекләндерү);
4) Каты коммуналь калдыкларны җыю (шул исәптән аерым җыю) һәм транспортлау эшчәнлеген оештыруда катнашу
( көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны җыюны, алып китүне һәм утильләштерүне оештыру);
5) җирлек территориясен төзекләндерүне оештыру (урамнарны яктырту өчен энергияне саклый торган лампалар һәм электр товарлары сатып алу, урамнарны яктыртуга хезмәт күрсәтү).

«РИЗА» «КАРШЫ».

3. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatar.ru.
3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Рәис: А. М. Мөхәмәтшин

**Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы**
**Чалпы авыл җирлеге Советы**
**КАРАРЫ**

Чалпы авылы № 72 25 сентябрь 2017 ел.

Чалпы авылы җирлеге биләмәсендә
узарасалым җыю һәм куллану буенча,
җирле референдум үткәрү
көнен билгеләү турында.

2002 елның 12 июнендә кабул ителгән "Россия Федерациясе гражданнарының референдумда катнашу һәм сайлау хокукларының төп гарантияләре" турындагы 67 номерлы Федераль законның 15 статьясы, 2003 елның 06 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле узидарәне оештыруның уртак принциплары" турындагы 113 номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 24 мартында кабул ителгән "Җирле референдум" турындагы 23 номерлы Татарстан Республикасы законы, Чалпы авыл җирлеге Уставының 12 статьясы, Чалпы авыл җирлеге башлыгының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 15 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары, Чалпы авыл җирлеге Советының 11 сентябрь 2017 елда чыккан 69 номерлы "Җирле референдум үткәрү" карары нигезләрендә,

Чалпы авыл җирлеге Советы карар кабул итте:

1. Чалпы авыл җирлеге биләмәсендә узарасалым җыю һәм куллану буенча 19 ноябрь 2017 ел көнне референдум үткәрергә.
2. Референдумда караласы мәсьәлә:
   "Сез, Чалпы авыл җирлеге биләмәсендә теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, 2018 елда 300 сум күләмендә узарасалым җыю белән килешәсезме. Узарасалым түләүдән көндезге якта укучы студентлар, 1 һәм 2 группа инвалидлар азат ителә. Узарасалымнан кергән керем түбәндәге юнәлештә тотыла:
   1) авыл эчендәге юлларны ремонтлау ( авыллар юлларына щебенка җәйдерү);
   2) жирлектэ яшәүчеләрнен ялын оештыру һәм мәдәният оешмаларынын хезмәте белән тәэмин итү өчен шартлар тудыру (бәйрәм чаралары оештыру һәм уздыру)
   3) жирлектэ яшәүчеләргә массакүләм ял итү өчен шартлар тудыру һәм массакүләм ял итү урыннанрын төзекләндерү, шулай ук гражданнарның су объектлары, су буйларыннан гомуми ирекле файдалануны тәэмин итү ( Чалпы авылында паркны төзекләндерү);

4) көнкүреш калдыкларын жыюда (шул исәптән аерым җыю) һәм транспорт белән чыгару эшчәнлеген оештыруда катнашу (көнкүреш калдыкларын һәм чүп-чарны жыю, чыгару һәм үтилләштеру);
5) авыл жирлеге территориясен төзеклэндерүне оештыру ( шул исәптән аз энергия сарыф итә торган лампалар һәм урам утларына электротоварлар алу, урам утларын карап тоту хезмәте күрсәтү).

“ӘЙЕ” “ЮК”

3. Карар районның “Маяк” газетасында бастырыла, хокукый мәгълүматның рәсми порталында Татарстан Республикасы буенча http://pravo.tatarstan.ru веб – адресы буенча һәм Азнакай муниципаль районының Интернет челтәрендә http://aznakyevo.tatarstan.ru веб – адресы буенча урнаштырыла.
4. Карар газетада бастырылып чыккан көненнән көченә керә.

Председатель: А.М. Мухаметшин